КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 12 ноябрь г.Казань № 1016

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 324 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 30 май, 443 нче; 2012 ел, 25 июль, 630 нчы; 2012 ел, 6 ноябрь, 969 нчы; 2013 ел, 7 март, 154 нче; 2014 ел, 16 май, 326 нчы; 2014 ел, 11 август, 580 нче; 2015 ел, 28 май, 386 нчы; 2016 ел, 26 февраль, 120 нче; 2016 ел, 19 сентябрь, 656 нчы; 2017 ел, 8 июнь, 361 нче; 2017 ел, 11 декабрь, 972 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1114 нче; 2018 ел, 27 сентябрь, 865 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1144 нче; 2018 ел, 20 декабрь, 1190 нчы; 2019 ел, 23 май, 433 нче; 2020 ел, 4 февраль, 74 нче; 2020 ел, 14 февраль, 109 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 нче пунктның икенче абзацында «677,6» саннарын «3026,513» саннарына алыштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 324 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 30 май, 443 нче; 2012 ел, 25 июль, 630 нчы; 2012 ел, 6 ноябрь, 969 нчы; 2013 ел, 7 март, 154 нче; 2014 ел, 16 май, 326 нчы; 2014 ел, 11 август, 580 нче; 2015 ел, 28 май, 386 нчы; 2016 ел, 26 февраль, 120 нче; 2016 ел, 19 сентябрь, 656 нчы; 2017 ел, 8 июнь, 361 нче; 2017 ел, 11 декабрь, 972 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1114 нче; 2018 ел, 27 сентябрь, 865 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1144 нче; 2018 ел, 20 декабрь, 1190 нчы; 2019 ел, 23 май, 433 нче; 2020 ел, 4 февраль, 74 нче; 2020 ел, 14 февраль, 109 нчы карарлары белән кертелгән

үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Министрлык функцияләре

3.1. Министрлык түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыру өчен җавап бирә:

Татарстан Республикасының тышкы икътисадый эшчәнлеге һәм ватандашлар белән мөнәсәбәтләр өлкәсендәге эшчәнлек белән идарә итү (01.03*);

энергияне һәм ресурсларны саклау белән идарә итү (01.14*);

сәнәгать белән идарә итү (03.01*), шул исәптән:

электр энергетикасы белән идарә итү (03.01.01*),

ягулык сәнәгате белән идарә итү (03.01.02*),

химия һәм нефть химиясе сәнәгате белән идарә итү (03.01.03*),

машина төзелеше һәм металл эшкәртү белән идарә итү (03.01.04*),

урман, агач эшкәртү һәм целлюлоза-кәгазь сәнәгате белән идарә итү (03.01.05*),

җиңел сәнәгать белән идарә итү (03.01.07*),

Татарстан Республикасының башка сәнәгать җитештерүләре белән идарә итү (03.01.10*);

эчке товар базарын аерым товарлар, хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүне җайга салу (03.05*);

эчке товар базарын аерым товарлар, хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүне җайга салу (этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүдән һәм аларны әйләнештә йөртүдән тыш) (03.05.02*);

ваклап сату базарларын оештыруга, ваклап сату базарларында товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) эшчәнлеген оештыруга һәм гамәлгә ашыруга бәйле мөнәсәбәтләрне җайга салу (03.05.03*);

социаль-икътисадый хезмәттәшлек мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү (03.07*).

3.2. Министрлык түбәндәгеләр белән үзара хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән сәламәтлек саклау белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.02*);

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.07*);

---

*Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторы буенча.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы белән урман фондын файдалану, саклау, яклау һәм урманнарны яңадан торгызу, урман үрчетү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салу функциясен гамәлгә ашырганда (01.06.04*);

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән мәгариф белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.05*);

Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.01*);

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы белән дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыру өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.07*);

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (03.02.01*);

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы белән физик культура һәм спорт өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.04*);

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән территориаль планлаштыру функциясен гамәлгә ашырганда (01.05.01*);

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән транспорт һәм юл комплекслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (03.03*);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән хезмәт белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.13*);

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән дәүләт финанслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.02*);

Татарстан Республикасының Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән цифрлаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15*);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы белән табигый ресурслардан файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.06*);

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

озак вакытлы этапка исәпләнгән социаль-икътисадый программалаштыру (01.01.01*);

планлаштырыла торган елга социаль-икътисадый программалаштыру (01.01.02*);

инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә җайга салу (01.09*);

инновацион эшчәнлекне үстерү белән идарә итү (01.11*);

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.03*);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.17*);

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты белән туризм өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.09*);

Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы белән дәүләти-хосусый партнерлык һәм хосусый инвестицияләр, инвестиция проектларын тормышка ашыруны комплекслы алып бару өлкәсендә инвестиция эшчәнлеген үстерү белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.10*).»;

4 бүлектә:

4.1.70 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.70. Казан, Түбән Кама, Чаллы, Зәй шәһәрләрендә һәм Урыссу шәһәр тибындагы поселогында «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең, «ТГК-16» акционерлык җәмгыятенең, «Түбән Кама җылылык-электр централе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылылык белән тәэмин итү чыганакларыннан җирлекләрнең һәм шәһәр округларының җылылык белән тәэмин итү системалары ышанычлылыгын арттыру чаралары системасын билгели.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.1.112 нче пунктча өстәргә:

«4.1.112. Үз компетенциясе чикләрендә инвесторлар тарафыннан махсус инвестиция контракты буенча йөкләмәләрнең үтәлешен Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 2016 ел, 21 апрель, ТРЗ-24 нче Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру буенча чаралар турында» 2018 ел, 15 декабрь, 1144 нче карарына, 6 нчы пункттагы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы сәнәгать тармаклары өчен махсус инвестиция контрактлары турында» 2018 ел, 20 декабрь, 1184 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы сәнәгать тармаклары өчен махсус инвестиция контрактлары турында» 2018 ел, 20 декабрь, 1184 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы сәнәгать тармаклары өчен махсус инвестиция контрактлары төзү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 25 апрель, 341 нче.

5. Бу карарның гамәле 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин